КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Тимершык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11.11.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, "ТР Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге" муниципаль берәмлек Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып, 2024 елның 11 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Тимершык торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Тимершык торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешләренә җибәрү турында:

А) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тимершык торак пункты чикләрендә вак таш белән капланган гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таш сатып алу, ташу, салу, су үткәрү торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Б) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Тимершык т.п. да Мишә елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 603 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 353 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 353 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Тимершык торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. “2025 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Тимершык торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Тимершык торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

А) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тимершык торак пункты чикләрендә вак таш белән капланган гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таш сатып алу, ташу, салу, су үткәрү торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Б) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Тимершык т.п. да Мишә елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы

А.Х. Хаҗиев